ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 408-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.В. Тыгин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 408-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 23 марты
№ 1900-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.В. Тыгин тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешендә:
а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8) Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, булдыру, карап тоту һәм алардан файдалану турында карар кабул итү;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $10^{10}$ пункт өстәргә:
«$10^{10}$) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $40^1$ статьясының 2 өлеше нигезендә архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү таләп ителми торган капиталь төзелеш объектларын билгеләү;»;

2) 5 статьяның 6 өлешендә «Интернет челтәрендәге рәсми сайттан» сүзләреннән соң «(алга таба – Интернет челтәрендәге рәсми сайт)» сүзләрен өстәргә, «территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасындагы» сүзләрен «территориаль планлаштыруның федераль дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – территориаль планлаштыруның мәгълүмат системасы» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяның $4^1$ өлешендә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Җирлекнең, шәһәр округының җирле үзидарә органнары шулай ук торак пунктлар чикләре урнашкан урынның текстлы тасвирламасын әзерләргә хокуклы. Торак

пунктлар чикләре урнашкан урынның график һәм текстлы тасвирламасы рәвешләре, торак пунктлар чикләренең характерлы нокталарының координатларын билгеләү төгәллегенә, күрсәтелгән белешмәләр кергән электрон документ форматына таләпләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясындагы $5^1$ өлеше нигезендә билгеләнә.»;

4) 10 статьяның 8 өлешендә «өч айдан» сүзләрен «бер айдан» сүзләренә алмаштырырга, «, ә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы $7^1$ һәм $7^2$ өлешләрендә каралган очракларда аны расларга кимендә бер айдан да соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ статья өстәргә:

«$10^1$ статья. **Җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларда шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын әзерләү һәм раслау**

1. Җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларда шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документы белән (алга таба шулай ук – бердәм документ) тиешенчә җирлекнең генераль планы, шәһәр округының генераль планы, шул исәптән җирлек, шәһәр округы, торак пункт өлешләре составына керә торган аерым торак пунктларга карата әзерләнгән, таныла, алар территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23 статьясы һәм әлеге Законның 9 статьясы нигезендә генераль планга кертелергә тиешле карталар белән беррәттән, шәһәр төзелешен зоналаштыру карталарын, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата шәһәр төзелеше регламентларын, шәһәр төзелешен зоналаштыру карталарын һәм шәһәр төзелеше регламентларын куллану тәртибен һәм аларга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы 3 өлешендә каралган нигезләмәләрне үз эченә алган үзгәрешләрне кертү тәртибен үз эченә ала.

2. Бердәм документка мәҗбүри кушымта булып әлеге Законның 9 статьясындагы $4^1$ өлеше нигезендә әзерләнә торган җирлек яисә шәһәр округы составына керүче торак пунктлар чикләре (шул исәптән төзелә торган торак пунктлар чикләре) турында, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 30 статьясындагы $6^1$ өлеше нигезендә әзерләнә торган территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр тора.

3. Бердәм документны әзерләү турындагы карар, бердәм документка үзгәрешләр әзерләү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актында бердәм документны әзерләү турындагы карар, бердәм документка үзгәрешләр әзерләү турындагы карар җирлекнең, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан кабул ителә дип каралган булырга мөмкин. Бердәм документ проектын әзерләү турында карар кабул итү белән бер үк вакытта бердәм документ проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ һәм 28 статьялары нигезендә аларны үткәргәндә бердәм документка үзгәрешләр кертү

оештыручысы булырга мөмкин бердәм документ проектын әзерләү комиссиясе составы һәм аның эшчәнлеге тәртибе раслана.

4. Бердәм документны әзерләү һәм раслау Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $28^1$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм документны әзерләү җирле администрация тарафыннан тәэмин ителә. Бердәм документ, аңа үзгәрешләр җирлек, шәһәр округы җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы тарафыннан раслана.»;

6) 17 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында «, муниципаль районның авылара территориясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ статья өстәргә:

«$18^1$ статья. **Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы**

1. Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләре нигезендә булдырыла һәм аннан файдаланыла торган мәгълүмат системасы, аңа территорияләрне үстерү турында, аларның төзелешен алып бару хакында, гамәлдәге һәм урнаштыруга планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары турында белешмәләр, документлар, материаллар һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка белешмәләр кергән.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, ул шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясындагы $7^1$ өлешендә күрсәтелгән документларны әзерләү, килештерү, раслау мөмкинлеген бирә, булдыру һәм аны алып бару турында карар кабул ителергә мөмкин.

3. Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, булдыру, үстерү һәм аннан файдалану мондый дәүләт мәгълүмат системасының операторлары булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә мондый орган карамагындагы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан тәэмин ителә.

4. Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән, алып бару Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (мондый орган карамагындагы дәүләт бюджет учреждениесе),

муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 57 статьясындагы 1[1] өлеше нигезендә күрсәтелгән органнар компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы территориясендә җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларда шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын гамәлгә ашыру максатларында эшләнде.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына кертелгән үзгәрешләр нигезендә 2022 елның 19 декабрендәге 541-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирлекне, шәһәр округын территориаль планлаштыруның һәм аларда шәһәр төзелешен зоналаштыруның бердәм документын (алга таба – бердәм документ) эшләү һәм раслау мөмкинлеге билгеләнде, ул үзендә генераль планның составын һәм эчтәлеген һәм җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен берләштерә.

Закон проекты белән «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына бердәм документны әзерләү һәм раслау тәртибен билгели билгели торган $10^1$ статья өстәргә тәкъдим ителә. Әлеге тәртип белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бердәм документны әзерләү һәм әлеге вәкаләтне җирлекнең, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына тапшыру мөмкинлеге белән аңа үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү күздә тотыла. Мондый карар кабул итү белән бер үк вакытта бердәм документ проектын әзерләү буенча комиссия составын һәм тәртибен раслау тәкъдим ителә, ул бердәм документ проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар оештыручы булырга мөмкин.

Закон проектында бердәм документны әзерләү җирле администрация тарафыннан тәэмин ителәчәк, бердәм документны раслау, шулай ук аңа үзгәрешләр җирлек, шәһәр округы җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы тарафыннан гамәлгә ашырылачак дип билгеләнә.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 56 статьясында Россия Федерациясе субъекты законы белән шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән Россия Федерациясе субъектлары шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системаларын булдыру һәм алардан файдалану мөмкинлеген билгеләү каралган, ул җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре; территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты; җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы; капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү һәм башкалар кебек документларны әзерләү, килештерү, раслау мөмкинлеге бирә.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның

автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү функцияләре белән Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм аны алып бару турында карар кабул итү мөмкинлеген беркетү тәкъдим ителә. Мондый дәүләт мәгълүмат системаларын булдыруны, үстерүне, алардан файдалануны алып бару һәм тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы яисә мондый орган карамагындагы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырылачак.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне кертү Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлеген нәтиҗәле җайга салуны һәм планлаштыруны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Закон проектында шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $40^1$ статьясындагы 2 өлешеннән килеп чыга торган архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү таләп ителми торган капиталь төзелеш объектларын билгеләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен төгәлләштерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр һәм редакция характерындагы аерым үзгәрешләр дә каралган.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә башкаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.